| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КИЛЬДЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>КИЛДИ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 20.09.2018 | 17 |

с. Кильдеево

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Килди авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. Килди авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү буенча уртак инициативаны тәкъдим итергә:

«2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны юллау белән килешәсезме?:

- Килди авылының Үзәк урамы буенча юлга вак таш салу;
- Уланово авылы зиратына кадәр вак таш җәю.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин